МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА,
АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-
КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА
ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 161/о

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«14» 06 2024

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июнендәге 69/о номерлы боерыгы белән расланган Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июнендәге 69/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 1 декабрендәге 176/о номерлы, 2023 елның 9 февралендәге 20/о номерлы, 2023 елның 28 декабрендәге 219/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, 2.6.1 пунктының 5 пунктчасында «экологик күзәтчелекне» сүзләрен «экологик контрольлекне (күзәтчелекне)» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Ж.Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин